КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 7 ноябрь г.Казань № 966

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 октябрь, 952 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1332 нче, 2022 ел, 21 сентябрь, 1022 нче, 2022 ел, 13 декабрь, 1321 нче, 2024 ел, 27 июнь, 472 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «46 543,0» саннарын «48 871,0» саннарына алмаштырырга;

7 пунктның беренче абзацында «13 323,0» саннарын «13 990,0» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин